## Декабрь аенда кояш чыгу, кояш бату һәм намаз уку вакытлары

| Көннәр | Иртәнге намаз | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Кояш бата Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 6.59 | 8.29 | 13.05 | 14.38 | 16.29 | 17.59 |
| 2 | 7.01 | 8.31 | 13.05 | 14.37 | 16.29 | 17.59 |
| 3 | 7.02 | 8.32 | 13.05 | 14.37 | 16.28 | 17.58 |
| 4 | 7.04 | 8.34 | 13.05 | 14.36 | 16.27 | 17.57 |
| 5 | 7.05 | 8.35 | 13.05 | 14.36 | 16.27 | 17.57 |
| 6 | 7.07 | 8.37 | 13.05 | 14.35 | 16.26 | 17.56 |
| 7 | 7.08 | 8.38 | 13.05 | 14.35 | 16.26 | 17.56 |
| 8 | 7.09 | 8.39 | 13.05 | 14.35 | 16.25 | 17.55 |
| 9 | 7.10 | 8.40 | 13.05 | 14.34 | 16.25 | 17.55 |
| 10 | 7.11 | 8.41 | 13.05 | 14.34 | 16.25 | 17.55 |
| 11 | 7.13 | 8.43 | 13.05 | 14.34 | 16.25 | 17.55 |
| 12 | 7.14 | 8.44 | 13.05 | 14.34 | 16.25 | 17.55 |
| 13 | 7.15 | 8.45 | 13.05 | 14.34 | 16.24 | 17.54 |
| 14 | 7.16 | 8.46 | 13.05 | 14.34 | 16.24 | 17.54 |
| 15 | 7.17 | 8.47 | 13.05 | 14.34 | 16.25 | 17.55 |
| 16 | 7.17 | 8.47 | 13.05 | 14.34 | 16.25 | 17.55 |
| 17 | 7.18 | 8.48 | 13.05 | 14.35 | 16.25 | 17.55 |
| 18 | 7.19 | 8.49 | 13.05 | 14.35 | 16.25 | 17.55 |
| 19 | 7.20 | 8.50 | 13.05 | 14.35 | 16.25 | 17.55 |
| 20 | 7.20 | 8.50 | 13.05 | 14.36 | 16.26 | 17.56 |
| 21 | 7.21 | 8.51 | 13.05 | 14.36 | 16.26 | 17.56 |
| 22 | 7.21 | 8.51 | 13.05 | 14.37 | 16.27 | 17.57 |
| 23 | 7.22 | 8.52 | 13.05 | 14.37 | 16.27 | 17.57 |
| 24 | 7.22 | 8.52 | 13.05 | 14.38 | 16.28 | 17.58 |
| 25 | 7.23 | 8.53 | 13.05 | 14.38 | 16.28 | 17.58 |
| 26 | 7.23 | 8.53 | 13.05 | 14.39 | 16.29 | 17.59 |
| 27 | 7.23 | 8.53 | 13.05 | 14.40 | 16.30 | 18.00 |
| 28 | 7.23 | 8.53 | 13.05 | 14.41 | 16.31 | 18.01 |
| 29 | 7.23 | 8.53 | 13.05 | 14.42 | 16.32 | 18.02 |
| 30 | 7.24 | 8.54 | 13.05 | 14.43 | 16.33 | 18.03 |
| 31 | 7.23 | 8.53 | 13.05 | 14.44 | 16.34 | 18.04 |

*Намаз вакытлары турында мәгълүматларны Самара өлкәсе мөселманнарының Региональ Диния нәзарәте хезмәткәрләре әзерләде, мөфти Вагыйз хәзрәт ЯРУЛЛИН раслады. Җомга көннәре аерып күрсәтелгән.*


**Учредители: трудовой коллектив редакции газеты «Бердэмлек» и Региональное Духовное управление мусульман Самарской области.**

**Оештыручылар: «Бердәмлек» газетасы редакциясенең хезмәт коллективы һәм Самара өлкәсе мөселманнарының Региональ Диния нәзарәте.**



بِسۡمِ اللّٰهِ الرَّحۡمٰنِ الرَّحِيمِ

# Кыйбла

„БЕРДӘМЛЕК" ГАЗЕТАСЫНЫҢ АЙЛЫК ДИНИ КУШЫМТАСЫ

№ 11
2012 ел
ноябрь




*ВӘГАЗЬ*

# 24 ноябрь — Гашура бәйрәме

Сүзебезне шуннан башлыйк: нәрсә соң ул Гашура көне? Мәгълүм булганча, Гашура көне мөхәррәм аеның унынчы көнендә билгеләп үтелә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мөхәррәм аеның унынчы көнендә, ягъни Гашура көнендә ураза тота торган булган. Бәгъзе дин галимнәре, Гашура көнне ураза тотуны Рамазан аеннан кала, ураза тотуның иң саваплы көннәре, диләр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм ике көн ураза тотуны мәгъкуль күргән. Гашура дип әйтүгә сәбәп шул, Аллаһы Тәгалә ун пәйгамбәрне әкрәм кылды, ягъни хөрмәтләде. Риване әхбар үә нәкыйлане асар, ягъни төрле хәбәрләрне сөйләүчеләр, төрле әсәрләрне күчерүчеләр тарафыннан вә дәхи 1890 елда Санкт-Петербургта басылып чыккан «Ху-ләсатүл-мәсәилә үә мүһәм-мәтүл дәләил» китабының 85 нче битендә бу көнгә бик күп истәлекле вакыйгалар туры килүе хакында әйтелә:

1. Җир вә күкләрне, оҗмахларны Хак Сөбханә вә Тәгалә Гашура көнне яралтты.

2. Гашура көнне Аллаһы Тәгалә гарше көрсине яралтты.

3. Гашура көнне Газзә вә Җәллә каләмне яралтты.

4. Гашура көнне Җәнабел-Хак Җәбраил фәрештәне, Микаил фәрештәне, Исрафил фәрештәне яралтты.

5. Гашура көнне Хак Тәгалә Адәм галәйһис-сәламнең тәүбәсен кабул кылды.

6. Гашура көнне Идрис галәйһис-сәламне «мәкән галиен»гә, ягъни Үзенең җәннәтенә күтәрде.

7. Гашура көнне Нух галәйһис-сәламнең көймәсе барча җир йөзен баскан туфан суыннан котылып, Җуди тавына килеп туктый.

8. Гашура көнне Ибраһим галәйһис-сәлам дөньяга килде һәм Гашура көнне Җәнабел-Хак аны Нәмруд утыннан коткарды.

9. Гашура көнне Ибраһим галәйһис-сәламнең углы Исмәгыйль туды.

10. Гашура көнне Йосыф пәйгамбәр коедан чыгарылды, һәм Гашура көнне Аллаһы Тәгалә аны әтисе Ягъкуб белән кавыштырды.

11. Гашура көнне Әюб галәйһис-сәлам 18 ел авырганнан соң, кортларыннан арындырылды.

12. Гашура көнне Муса галәйһис-сәлам Аллаһы Тәгаләнең ярдәме илә фиргавеннең эзәрлекләвеннән котылды. Фиргавен Нил дәрьясында гарикъ булды, ягъни батып үлде.

13. Гашура көнне Дауд галәйһис-сәламнең тәүбәсе кабул ителде.

14. Гашура көнне Аллаһы Сөләйман пәйгамбәргә падишаһлыгын кайтарды.

15. Гашура көнне Йуныс галәйһис-сәламне Хак Тәгалә балык карыныннан коткарды.

16. Гашура көнне Гайсә галәйһис-сәлам туа, һәм Аллаһы Тәгалә аны үлемнән коткарып, күккә күтәрде.

Ошбу китерелгән мисаллардан күренгәнчә, Гашура көнендә бик күп изге гамәлләр кылынган. Бәс, шулай булгач, барча мөселманнар бу көнне зурлап бәйрәм итәләр.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәлам һәм сәхабәләр ошбу көнне мөбарәк санап, ураза тотмышлар. Күп пәйгамбәрләрнең догалары бу көндә кабул булып, бик зур афәт вә бәлаләрдән котылуларына сәбәп булган өчен, Гашура бәйрәме мөбарәк бер көн санала.

Теләгән кешеләр, Гашура көнендә ураза тотып, савап җыялар. Шул көндә, ягъни мөхәррәм аеның 10 нчы көнендә яһүдиләр дә ураза тотканлыктан, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: *«Сез, 9 нчы вә 10 нчы көннәрдә ике көн ураза тотып, яһүдиләрдән аерылып торыгыз, аларга охшамагыз»,* – дигән.

Мөхәммәд галәйһис-сәлам әйткән: *«Бер кеше Гашура көнен хөрмәтләп ураза тотса, Аллаһы Тәгалә ул кешегә фәрештәләргә вә изгеләргә булган савапны насыйп итәр».*

Гайшә радыйаллаһу ганһәдән риваять кылынадыр: Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: *«Кем дә кем Гашура көнендә йөз рәкәгать намаз укыса, ул кеше вафат булгач, Аллаһы Тәгалә ул кешенең каберен хуш ис белән тутырыр»*, – дигән. *«Намаз укучы кеше һәр рәкәгатьтә «әл-Фатыйха» сүрәсеннән соң өч мәртәбә «Ихлас» сүрәсен укыр, намаз соңында «Сөбханаллаһи үәлхәмдү лилләһи үә лә иләһә илләл-лаһү үәллаһү әкбәр. Лә хәүлә үә лә куввәтә илләә билләһил-галиййил-газыййм», дип җитмеш мәртәбә әйтер. Дәхи кәлимәи истигъфарны җитмеш мәртәбә әйтер.*